Мөхәммәдшакир Тукаев

# ЭСТӘРЛЕБАШ ТАРИХЫ

АЛТЫН МИРАС

КАЗАН
2010

[illegible]
БИБЛИОТЕКА»
[illegible] Стерл[illegible]
[illegible] Башкортостан

**Әдәби мөхәррир:**
Филалогия фәннәре докторы
Марсель Әхмәтҗанов

**Мөхәммәдшакир Тукаев**
Эстәрлебаш тарихы. — М.: ООО «Алтын Мирас», 2010. – 32 с.

ISBN 978-5-904820-02-2

Рекомендуется для широкого круга читателей.
Все права защищены.

**ООО «Алтын Мирас»**
г. Казань, ул. Нариманова, 98
тел. 8 (909) 9149697
altinmiras@yandex.ru

ISBN 978-5-904820-02-2
© ООО «Алтын Мирас» 2010

بسم الله الرحمن الرحيم

Эстәрлебаш авылы – губернасы булган Өфе шәһәреннән йөз илле чакрым җирдә, өяздә булган Эстәрлетамак шәһәреннән илле чакрым кыйбла тарафында, Олугъ Себер тимер юлында барлыкка килгән Шәфран станциясенннән җитмеш биш чакрым җирдә, якынча 73° озынлык 52° киңлек арасында Эстәрлебаш суының башланган җиреннән биш чакрымда барлыкка килгән бер мәшһүр авылдыр. Әүвәл заманнарда ошбу башкорт җиренә Казан якларыннан һәм Каргалы шәһәреннән кайбер кешеләр солых һәм мәслихәтләре белән килеп сәүдә һәм кәсепләр белән шөгыльләнер өчен ошбу Эстәрлебаш урынында утар ясап яшәгәннәр. Акрынлап кәсеп һәм сәүдәләре алга барганлыктан кешеләр күбәеп авыл булып киткән. Бу вакыйга кайсы заманнарда һәм ничәнче елларда булганы мәгълүм булмаса да, Эстәрлебаш авылы Пугач вакыйгасыннан йөз еллар элек булган имеш, диләр. Пугач вакыйгалары безнең бу якларда 1773 нче елларда булган.

Эстәрлебаштан өч чакрым җирдә Бускун дигән урын Пугач вакыйгасында качып һәм яшеренеп калганнан исемләндерелгән дип сөйләнелә. Кайбер кешеләрнең әйтүенә күрә, Эстәрлебашта элек яшәгән кешеләр бераз заман торгач җирне башкортлардан иҗарәгә[1] алганнар. Иҗарәләре илле елга булган имеш. 1809 нчы елның 25 нче апрелендә язышкан кәгазьләре Әбүн-нәгыйм Мөхәммәдлатыйф улы дигән кешенең кулында булган. Аның бабасының бабасы Йосыф-купец дигән кеше Каргалыдан килеп, сәүдә итеп, поташ заводы тоткан. Мәгълүм кәгазьне 1809 нчы елда башкортлар белән ул язышкан; ошбу кәгазьне өченче мәртәбә алу имеш; һәр мәртәбәдә иллешәр елга язышканнар, дип әйтәләр. Шуңарга таянып башкортлардан алынган кәгазь белән 1809 нчы елдан йөз ел элек ала башлап кәгазьсез утыз еллар торган булсалар Эстәрлебаш 1680 нче еллар чамасында нигезләнгән булырга тиеш. Әмма Саки, кайсы кешеләр ошбу вакыттагы кешеләрнең нәселе һәм бабалары булганнары күрелми һәм беленми. Пугач вакыйгаларыннан соңрак булган эшләрне белүче әби-бабайлар бер егерме биш ел элек заманнарда бар иде, һәм кайбер кешеләрдә электән сакланган язулар арасында 1774 нче һәм

[1] Иҗарә-аренда



1797 нче еллардагы кайбер мөгамәләт кәгазьләре (документлар) бар.

Эстәрлебаш авылы, төн яктан биек тау буенда, Эстәрле елгасының ике ягында җирләшкән авылдыр. Кыйбла һәм шәрекъ тарафында ачык һәм аз-аз урманнары бар: урыны биек җирдә һәм төньяктан тау белән әйләндереп алынганы өчен, Эстәрлебашта хуш һава булып җимеш бакчалары бардыр. Бакчаларда алма, груша кебек җимешләр пешеп өлгерәләр. Мәшһүр хәзрәтләр бакчасы белән мәгълүм олугъ бакчалардан башка тагын да дүрт-биш җирдә алма үсә торган бакчалар бар. Уртача кышларда суыклык унике градуска туры килеп, җәй көннәре җылы вакытларда уртача унҗиде градуска туры киләдер.

Эстәрлебашның халкы татар халкыдыр. Авыл халкының күбесе ашлык чәчеп кәсеп итәләр, һәм кайбер сәүдә итүчеләр дә бар. Кайбер кешеләр җәй көннәрендә урак һәм печән кәсепләре өчен, ялан-якынга бару кәсебе дип, Оренбург һәм Самара тарафына барып, бер-ике ай кәсеп итеп, кеше башына уртача хисап ителгәндә ун һәм унбиш сум акча кәсеп итеп кайталар. Халык арасында кайбер сәнгать һәм һөнәр ияләре дә бардыр, унга якын ташчы һәм миччеләр, һәм шулай ук унга якын читек-кәвеш тегүчеләр һәм унлап балта осталары, һәм унбишкә якын пычкычылар бардыр; Эстәрлебашта хатын-кызлардан да

кайбер чигү-тегү һәм палас сугуга осталары бардыр. Эстәрлебаш авылында 1897 елдагы гомуми санау буенча 1072 ир, 1052 хатын, һәммәсе 2124 кеше күренде. Иншаллаһ, хәзер дә шул кадәр, бәлки дә күбрәк кеше бардыр. Эстәрлебашта һәр дүшәнбе көн атнада бер мәртәбә базар үткәрелеп, сәүдәгәрләр арасында уртача җиде йөз тәңкәлек кадәр нәрсә сату тәҗрибә кылынадыр.

Эстәрлебаш авылы мәшһүр авыллардан булып санала; шөһрәте олугъ мәдрәсәләрендә бер елда ничәшәр йөз шәкертләр заһири гыйлемнәр өйрәнеп һәм ничәмә йөзләр батыйни гыйлемдә үзенең өлешен алып, йөз елдан күбрәк бәлки ике йөз елга якын Эстәрлебаштан күп галим һәм голяма һәр якка таралып, мөселманнар арасында гыйлем һәм әхлак тараталар. Эстәрлебаш авылына беренче мәртәбә имам булып Монасыйп мулла исемле кеше килгән имеш дип әйтәләр; ул кеше хакында мәгълүм булган хәбәрләр һәм нәселендән кемнәр калганыннан белеп хәбәр бирер кеше булмады. Мәзкүр Монасыйп мулла 1710 нчы ел белән 1720 нче еллар арасында имам булып торган булырга тиеш. 1720 нче еллардан соң Эстәрлебашта мәчет салынып, әүвәл мәдрәсә төзеп дәрес башлаган кеше Хөсәен мулла Габдуррахман улыдыр. Мәрхүм беренче мәртәбә Эстәрлебашта мәчет төзетеп җомга укый башлап, бугенге көндә Эстәрлебаштагы минбәр таягы ошбу Хөсәен



хәзрәттән калган таяктыр. Шул минбәр таягында язган язуы бар: “Хөсәен бин Габдуррахман” дип язган; 1870 нче елларда бу таякка йөз илле ел бар дип әйтәләр иде. Бик белеп сөйләгән бер кешенең әйтүенчә мәзкүр Хөсәен мулла беренче мәртәбә мөфти булып килгән, Мөхәммәдҗан мөфти Хөсәеновның атасыдыр. Мөхәммәдҗан мөфти олугъ Екатерина Икенченең әмере белән 1789 нчы елда мөфти булып килгән. Ошбу югарыда әйтелгәннәргә таянып Хөсәен мулла якынча 1720 нче елларда Эстәрлебашта дәрес укытырга башлаган, шул вакытларда мәчет һәм мәдрәсәләр төзелгән. Шулай булгач Эстәрлебаш мәдрәсәсенең тарихын 1720 нче еллардан хисап кылырга ярый. Ошбу Хөсәен мулла хәзрәтләре кайсы елларда вафат булганы турында белгән кешеләр булмады, һәм ничә ел дәрес биргәне беленмәде; әмма ки салих һәм галим амири билмәгъруф (Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәүче) кеше булган дип әйтәләр (рәхмәтуллаһи галәйһи). Эстәрлебашта икенче мәртәбә мөдәррис булып дәрес бирүче кеше Гаделшаһ хәзрәт бине Габдуллаһ Богданов[1] булган. Ошбу Гаделшаһ хәзрәт мәшһүр Чебенледәге Ниязколый әт-Төркмәнинең хәлифәсе булган Дәүләтшаһ хәзрәтнең

[1] Гаделшаһ хәзрәт бине Богданов (1732–1812) Эстәрлебашында имам һәм шәйх булган кеше, чыгышы белән Бөре ягыннан

(рәхмәтуллаһи галәйһи) атасыдыр. Гаделшаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) хакында мәгълүм булган хәбәрләрдән Чакмакта Габдуллаһ хәзрәт мәрхүм (рәхмәтуллаһи галәйһи) шулай дип әйтә иде: Минзәлә өязендә Урыш-Мөслим авылында Шәмгун мулла дигән кеше, Эстәрлебашта Гаделшаһ хәзрәтнең мәдрәсәсендә укып кайтып указный имам булып торып, сиксән биш яки туксан яшьләр чамасында 1860 нчы елда, вафат булган. Мәрхүм Шәмгун мулланың Эстәрлебашта торган заманлары 1795 нче еллар чамасында булырга тиеш. Һәм Балыклы авылында мәшһүр булган Хөснетдин ахунд[1] хәзрәт мәрхүмнең Гаделшаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) мәдрәсәсендә 1799 нчы елда язган китабы бар. Ошбу әйтелгәннәргә күрә Гаделшаһ хәзрәт 1785 нче елларда, бәлки тагын да элегерәк яшәгән булса кирәк. Хөсәен мулладан соң Эстәрлебашта Гаделшаһ хәзрәткә кадәр, ягъни аларның икесе арасында мөдәррис булдымы-юкмы, яки Хөсәен мулла бик карт булып Гаделшаһ хәзрәт аңардан соң мәчет һәм мәдрәсәләргә хәлифә булып калганмы икәнен белгән кеше булмады. Гаделшаһ хәзрәт заманында Эстәрлебаштан төрле фәннәрне белүче галимнәр чыгып, араларыннан игътибар

[1] Хөснетдин ахунд Жданов (1767–1869) Нигъмәтуллаһ Тукаевның кияве, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә белем алган, Балыклыкүл авылында мәдрәсә тоткан.



ияләре чит җирләрдә дәрес бирә башлаганнар, шул заманнан, ягъни якынча 1700 нче еллардан башлап, Эстәрлебаштан галим кешеләр чыга башлаган, бәлки аннан элегерәк дип тә хисап кылырга мөмкин. Гаделшаһ хәзрәт 80 яшендә, 1812 нче елда вафат булган. Гаделшаһ хәзрәт ахунд булган имеш диләр. Мәрхүм галим гамил һәм дәрескә гаять дә оста һәм тәкъва адәм иде дип әйтәләр (рәхмәтуллаһи галәйһи). Гаделшаһ хәзрәт заманында һәм бераз Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында улы Дәүләтшаһ хәзрәт Эстәрлебашта бик тырышлык белән дәрес укыткан һәм аннан соң Бохараи шәрифкә киткән диләр. Гаделшаһ хәзрәттән соң Эстәрлебашта шәйх Нигъмәтуллаһ хәзрәт вәләде Биктимер вәләде Тукай (Бәктә хәзрәт исеме белән мәшһүр рәхмәтуллаһи галәйһи) булгандыр. Мәрхүм хәзрәт 1773 нче елларда туып 1801 нче елларда Бохараи шәриф якларына заһир һәм батыйн гыйлемнәр өйрәнер өчен киткәннәр. Шул 1801 нче елда Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) Эстәрлебаштан март аенда чыгып киткәне кайбер иске кәгазьләрдә язылганы күренәдер. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт Бохараи шәрифкә барыр алдыннан Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахунд хәзрәттә укыган. Гаделшаһ хәзрәт вафатыннан соң 1812 нче елдан башлап, 1813 нче елның 22 нче августында указ алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә мөдәррис

һәм мәчетендә имам булып, заһир гыйлемнән дәрес биреп голүме тарикать вәл-хакыйкатьтә (тарикать гыйлемендә) мөршиде камил һәм шәйхе фазыйл булып кешеләрне туры юлга өндәү белән шөгелләнеп, заманында көче җиткәнче бидгатьне егуда һәм һәртөрле җәмгыять катлавындагы кешеләрне рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте буенча яшәүгә өндәүдә бик күп тырышлык сарыф итте. Тирә-якта җыеннар, нәүрүз көннәрендә туй үткәрүдән тыелулар, мәеттән соң өченче, җиденче һәм кырыгынчы көннәрдә аш үткәрүләр кебек нәрсәләрне бетерүләр, ишрак халкалары[1] һәм игътикәфләрнең халык арасында таралуы Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) тырышлыгы белән башланган иде диләр. Бу тырышлык исә "...Мән сәннә сүннәтән хәсәнатән фәләһу әҗрүһә вә әҗрү мән гамилә биһә..." хәдиси шәрифенең растлавы буладыр. Нигъмәтуллаһ мәрхүм хәзрәт заманында Эстәрлебаштан күп галимләр заһири һәм батыйни гыйлемне өйрәнеп, төрле якларга таралдылар. Заманында укыган, укымаган, галим һәм надан, фәкыйрь һәм җитәкчеләрнең күбесе мөселман иде. Эстәрлебашка килгән олугъ кешеләрдән берсе мәрхүм Җиһангир хан һәм

[1] Ишрак халкалары — кояш чыгып 45 минут үткәннән соң түгәрәк саф рәвешендә утырып зекер итү



Ширгази хан[1] иде дип әйтәләр. Җиһангир ханның улларыннан берсе, 1840 нчы еллар чамасында, Эстәрлебашта мәдрәсәдә гыйлем алган. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында Эстәрлебашта гыйлем күтәрелеп шәкерт күбәя башлаганлыктан, мәчет һәм мәдрәсәләрне зурайтырга хаҗәт төшеп, мәчет һәм мәдрәсәләр өчен күп акча, ярдәм һәм тырышлык сарыф ителгән. Мәчет әүвәлге урыннан йөз таяк кадәр түбәнрәк, авылның уртасына күчереп салынган. 1814 нче елда, мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт заманында, Эстәрлебашта бакчаларда агачлар утыртыла башлаган. Шул заман утырткан карагайларның барысы хәзер дә үсә. Агач гыйлемен белүчеләр карагайларны 80 яки 90 еллык диләр. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманында Эстәрлебашка 1836 нчы елда фонтан китертелгән, шул фонтан хәзер дә бардыр. Китерелгәннән бирле өч мәртәбә тәгъмир (ремонт) кылынды; суыннан шул көннән бу көнгә кадәр һәр көн ничә мең җан инсан һәм хайван файдаланып торалар (Аллаһу Тәгалә сәвабын насыйп итсен). Нигъмәтуллаһ хәзрәт гыйльме батыйнда камил булып, күп вакыт тарикать гыйлеме белән шөгелләнеп, гыйльме заһирга кәмаль тырышлык күрсәтә иде. Заманында басмаханә һәм китаплар

[1] Җиһангир хан Бүкәй хан углы (1802–1844) вә Ширгази хан – казах ханнарыннан.

аз булганлыктан, китаплар сатып алыр өчен күп тырышлык һәм маллар сарыф итте диләр; үз кулы белән язган җыентыклары бардыр, һәр җирдән һәм һәр фәннән нәкыль-күчермәләре бар. Заманында тәфсире Казыйдан[1] дәрес алганы өчен тәфсире Шәйхзадә нөсхәсен күчертеп алырга Эстәрлебаштан Бәйрәкәгә билькасд (ниятләп) барып кайтты диләр; заманыннан калган Эстәрлебашында язылган һәм Бохараи шәрифтән алдырган күп кульязма китаплар бу көнгә кадәр сакланган.

Мәрхүм Нигъмәтуллаһ хәзрәтнең 1810 нчы елда олы улы Мөхәммәтхарис хәзрәт дөньяга килде: 1814 нче елда икенче улы туды, Мөхәммәдхәррас дип исем бирелде. 1833 нче елда улы Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) Бохараи шәрифкә Оренбургның генерал — губернаторы тарафыннан, 1833 нче елның 24 нче сентяберендә Бохарага барырга бирелгән 1380 нче номерлы рөхсәт кәгазе белән заһир һәм батыйн гыйлем өйрәнер өчен сәфәргә чыкты, 1841 нче елда гыйлем алып исән-сау кайтты; 1841 нчы елда июльнең 14 нче көнендә "Ыргыз буендан сәламәт бу йиргә килдек" дип язган ха-

[1] Тәфсире Казый — бөек галим Бәйзавый (вафаты һиҗри 685 елда) хәзрәтләренең, Коръәни Кәрим аятьләрен җитди шәрехләгән зур күләмле хезмәте.



ты бар. 1841 нче елда шәйх Нигъмәтуллаһ улы Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) Бохараи шәрифтән заһир һәм батыйн гыйлемнәрне өйрәнеп һәм әхлакы хәмидә алып сау-сәламәт кайтып, шул ук елны дәрес укытырга башлап бер-ике елдан соң яран (дуслар, мөрид) тәрбия итәргә башлады диләр. 1844 нче елда икенче улы Мөхәмматхәррас мәрхүм (рәхмәтуллаһи галәйһи) хәзрәтләре Бохараи шәрифкә гыйлем алыр өчен сәфәргә чыкты; ул елларда Эстәрлебашта җәмгыять күп иде, һәр яклардан гыйльме заһир һәм гыйльме батыйн алыр өчен килгән шәкертләр кәмаль тырышлык белән гыйлем һәм әхлак өйрәнеп, хосуси буларак әдәп ягыннан иң югары дәрәҗәләргә ирештеләр. 1844 нче елда, һиҗрия белән 1290 нчы елда кәттә хәзрәт шәйх Нигъмәтуллаһ Биктимер улы (рәхмәтуллаһи галәйһи) хәзрәтләре 27 нче март көнне җитмеш өч яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчтеләр. Мәрхүм гаять галим, гамиле мөттәкый (тәкъва) һәм шәйхе камил, амири билмәгъруф вән-нәһи ганил мүнкәр (Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелган), Рәсүлуллаһның сөннәте белән шөгелләнеп, хадимул-гыйльм (гыйлем хезмәтчесе) һәм мөршиди камилләрдән (иршад итүчеләрдән) иде. Мәрхүм Нигъмәтуллаһ ишан хәзрәттән соң улы Мөхәммәдхарис Нигъмәтуллаһ

улы (Ишан хәзрәт исеме белән данлыклы) Эстәрлебашта имам, мөдәррис һәм Эстәрлебашның шәйхе булды. Мөхәммәдхарис хәзрәткә кануни указ алганчыга кадәр Оренбург мөфтие тархан Габделвахид Сөләйманов хәзрәтләре тарафыннан 1844 нче елда 4 нче апрельдә Эстәрлебаш авылында мәчеттә имам булып һәм мәдрәсәләрдә һәр фәннән дәрес укыту өчен дип бирелгән рөхсәт кәгазе бардыр. Шаять шул елларда кануни указ да бирелгән мөгаен. Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтләре 1810 нчы елда дөньяга килеп, 1833 нче елда Бохараи шәрифкә барып гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнеп, 1841 елда сәламәт кайтып дәрес укыта һәм тәгълим кыла башлап шәехлек дәрәҗәсенә ирешеп, 1844 нче елда атасының урынына камил хәлифә булып калдылар. 1846 нчы елда Каргалыда Габдуллаһ кантун Дәүләтшаһ Чынлы улы хәзрәтләренең кызын алып кияү булдылар. Мәзкүр Габдуллаһ кантун мәхдүм акыллы, әһле фирасәт (зиһен иясе) һәм игътибарга лаек кеше иде, 1883 нче елда вафат булды. Мөхәммәдхарис хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманында Эстәрлебашта һәр фәннән дәрес укыту һәм тәгълимләр күбәйде, хәлфәләр күп булып һәр кайсысы төрле фәннән дәрес укытып китабәт һәм мөкаләмә кылышу (гарәпчә язу һәм сөйләшү) мәшһүр булды. Хәлфәләрнең һәркайсысы



үзләренә махсус мәдрәсәләрдә шәкертләргә һәр кайсының дәрәҗәсенә күрә дәресләр өйрәтеп, шәкертләр исә хәзрәтнең дәресенә вакытында һич соңга калмыйча хәзер булалар иде; бу дәресләр гыйльме-Осуль һәм Хәдисдән, Тәүзыйх, Тәлхис, Мишкәт һәм Тәфсире Казыйдан булалар иде. Укучылар арасында галимнәре һәм сүзләшергә тырышучылары, хәзрәттән рөхсәте камил һәм ишарә алып, дәресләрдә күп мөкаләмә (гарәпчә сөйләшеп) һәм һәркем үз белгәненчә тәкърирләр кылып (дәрес аңлатып), кайбер дәресләр ике-өч сәгатькә кадәр хәттә тагын да күбрәк вакытка сузыла иде. Бу заманнарда Эстәрлебашка гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнер өчен килүчеләр элеккесеннән күбрәк булды. Кыргыз якларыннан, Минзәлә, Оренбург һәм Казан тирәләреннән һәр төрле голяма, эгъния, үмара һәм гавамнардан (галим, бай, җитәкче һәм гади халык арасыннан) күп кешеләр кайберләре гыйльме заһир һәм батыйн өйрәнер өчен, кайберләре дә изһару ухуввәт филләһ (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якынлык күрсәтү) өчен киләләр иде... Бу заманнарда кәттә хәзрәт (рәхмәтуллаһи галәйһи) вакытларыннан калган Эстәрлебаштагы мәчеткә җәмагать сыймый башлады; шул сәбәптән олы бүлмәне 1858 нче елда төзеделәр, эченә дүрт йөзгә якын кеше сыядыр. 1852 нче елда энесе Мөхәммәдхәррас

Нигъмәтуллаһ улы хәзрәтләре Бохараи шәрифтән сау-сәламәт әйләнеп кайтып гыйлем таратуга кереште. Бу вакытлар Эстәрлебашның шөһрәт тапкан вакытларыннан иде. Һәр яктан Эстәрлебашка галимләр арасыннан күп кешеләр килеп мөслим (мөселман) булып Эстәрлебашны мактыйлар иде. Мәрхүм Габдессәлям һәм Габделвахид мөфти хәзрәтләре Эстәрлебашына берничә тапкыр килделәр диләр; мөфти Сәлимгәрәй Тәфтилев хәзрәтләре дә Эстәрлебашны яратучылардан берсе иде; Эстәрлебашында өй төзетеп үз теләге белән килеп торыр иде; соңыннан өен вакыф[1] итеп калдырды (Аллаһы Тәгалә кабул итсен). Галим һәм игътибар иясе кешеләр арасыннан Килем Хөсәен хәзрәт, Урманай[2] Габделгазиз хәзрәт, Бикбау[3] Габделгалим хәзрәт, Чакмак[4] Габдуллаһ хәзрәт, Бәйрәкә Габделгали хәзрәт, Мәчти[5] Әхмәдҗан хәзрәт һәм Такталачык[6] шәйхе Фазлуллаһ хәзрәтләр (рәхмәтүллаһи галәйһим әҗмәгыйн) һәр ел Эстәрлебашка килеп, бераз торып, гыйлем таратып һәм изһарү хуб филләһ кылып (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якын-

[1] Вакыф — берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек

[2] Урманай – Татарстанның Минзәлә төбәге.

[3] Бикбау авылы – Татарстанның Минзәлә төбәге

[4] Чакмак – Татарстанның Мөслим төбәге.

[5] Мәчти – Татарстанның Актаныш төбәге.

[6] Такталачык – Татарстанның Актаныш төбәге.



лык күрсәтеп) китәләр иде. Эстәрлебашта шәкерт күп булганлыктан, Мөхәммәдхарис хәзрәт мәрхүм заманында күп мәдрәсәләр яңадан төзелде, таштан суханә төзелеп, өстендә Мөхәммәдхаррас хәзрәт өчен дәресханә төзелде. Хәлфәләрнең барысы дәрестә куәтле булганыннан һәм Мөхәммәдхарис хәзрәт Эстәрлебашта икенче имам өчен указ алып тарикать гыйлемен тараткач, дин һәм дөнья иң югары мәртәбәләргә ирешкәннән соң, Мөхәммәдхарис хәзрәт Хаҗ сәфәренә барырга ният иттеләр. 1859 нчы елның 24 декаберендә Оренбургның генерал-губернаторы тарафыннан рөхсәт, ягъни Хаҗ билеты бирелеп, 1860 нчы елда Хаҗ сәфәренә чыкты. Сәфәрдә Шам Шәрифкә һәм Мәдинә-и Мөнәүвәрәгә барып, Хаҗ кылып, 1860 нчы елда сау-сәламәт кайтып җиттеләр. Билетында 3 нче августта Истанбулда, 1860 нчы елда 11 нче августта Адиста (Одессада) дип язылган билге күренәдер. Хәзрәт сәфәргә чыкканда озата баручы дуслары һәм кайткан вакытта каршы алыр өчен килүчеләр 3000 меңнән күбрәк булды дип әйтелә. Хаҗ сәфәреннән исәнлек-саулык белән күп китаплар алып кайтты. Хаҗдан соң Мәккә һәм Мәдинә тәртибенә күрә рамазан шәрифнең ахыргы ун кичендә тәравих намазы вакытында хәтем булып, сәхәрдән соң толуге фәҗердә (иртәнге намаз вакытында) хәтме "Сәхихи Боха-

ри" (Сахихи Бохари исемле хәдис китабы хәтме) булып дога мәҗлесе була иде. Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәт ике-өч мәртәбә Казан ягына чакырылып кунак булып, һәм өч мәртәбә Урал өлкәсе, ягъни Җаекъ тарафына, беренче мәртәбә 1863 нче елда Глинни дигән җиргә Исәнбаевлар гайләсе чакыруы белән махсус кунак булып барды; һәм киләсе елга шул ук Исәнбаевларның улы Габдуллаһ мәхдүмгә никәх кылу өчен туй мәҗлесенә барды; 1870 нче елда Җаек кальгасенә Әбүбәкер белән Габбас Белоусовларга улы Гобәйдуллаһ мәхдүмгә кыз ярашырга туйга барды; барганда һәм кайтканда юлда һәм барган җирләрдә һәр яктан галим, бай һәр төрле кешеләрдән торган җыелышлар булды дип сөйлиләр; бу елларга кадәр шул мәҗлесләрне күргән һәм сәфәрләрдә булган кешеләр һәр кайсылары бу вакыйганы шатлык һәм мәхәббәт белән зикер итәләр. 1893 нче елны Ялпакталга барган вакытыбызда казакъ картларыннан бер карт мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтләре бу якларга килгән вакытларында мәҗлесләрендә булган бер казакъ карты безгә: "Балалар Локман Хәким[1] мең ел яшәде дип әйтәләр, әмма ки ул мең ел тормаган икән, һәр мәҗлесенә карап кайберен бер елга, кайберен биш елга хисап итеп

[1] Локман Хәким – Коръәни Кәримдә телгә алынган шәхес.



мең яшь шуның белән хисап иткән икән, әмма ки сезнең бу Мөхәммәдхарис хәзрәтнең мәҗлесенә катнашырга мөмкинчелегез булды, сез мең яшәдегез, гафил булмагыз, ганимәт (бәхетле кеше икәнегезне) белегез,"– дип әйтә иде. Мөхәммәдхарис хәзрәт галим, гамил (гыйлеме белән гамәль итүче), тәкъва, матур һәм килешле итеп аңлатып сөйләүгә оста, гүзәл холык иясе һәм гаять тә юмарт булып, яхшылыклары һәр төрле кешегә берүк тигез иде, йортында һәрвакыт ничәмә кешеләр кунак булып, кайбер көннәрдә йөзләп кеше дәстәрханыннан сыйландылар. Бу юмартлыгыннан башка, гыйльме тыйбтан (медицина) насыйбы булганыннан ничәмә авыруларны дәва итеп, киемсезләргә кием биреп, утарханә дигән урында кырыкка якын ятимнәр һәм фәкыйрьләр өчен фәкыйрьханә тотып, ничәмә еллар аларны туйдырып асрады. Бер ачлык елны тирә-якта иген һәм бәрәкәт булмавыннан ачлык белән интеккән халыкка бер елда өч мең пот кадәр ашлык таратты диләр. Хәзрәтнең шөһрәте, һәр кемгә булган яхшылыгы һәм дәүләткә каршы мәхәббәте мәэмүрләргә (чиновникларга) мәгълүм булып, бөек падишаһ хәзрәтләренә җитешеп, император Александр әс-сани (икенче) хәзрәтләре 1869 нчы елның 16 нчы августында биргән әмере белән тарханлык дәрәҗәсенә иреште. Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең Эстәрлебаштагы би-

налары арасыннан истәлек итеп кешеләр һәм хайваннар өчен, ак таштан юнып, гөмбәз белән эшләнгән зур таш күпере бар. Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәт гыйльме, хильме һәм юмартлыгы белән һәркемнең игътибарына лаек булып үз заманында әмри билмәгъруф вән-нәһи ганил-мүнкәрләрдә (Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелуда) сүзе һәр кешегә үтә иде: заманының мәэмүрләре (чиновниклары) кайбер старшиналарны хәзрәт янына әдәп алыр өчен җибәрәләр иде. 1869 нчы елда Оренбург якларында сәхрә казакълары арасында талаш һәм тынычсызлыклар мәйданга килгәндә, Оренбургның генерал-губернаторы Крыжановский тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтне чакырып: “Сезләрне сүзе үтүче кеше дип ишетәбез, казакъларга мәслихәт итеп араларында үтерешү булмасын,”– дип һәм тынычлык эчендә яшәүләре өчен өндәп кәгазь язуын үтенүе буенча, шул 1869 нчы елның 23 нче хәмәлендә[1] казакъларга нәсыйхәт язды; һәм шул нәсыйхәт буенча казакълар тынычсызлыкны ташлап иминлеккә ирештеләр. Эстәрлебашта шул кәгазьнең нөсхәсе бар, имзасы һәм пичәте бар; нөсхәсендә күбрәк Ислам дине һәм милләт куәтләндерү өчен тынычлык кирәк дигән сүзләр язылган. Мәрхүм тархан

[1] 22 нче марттан 22 нче апрельгә кадәр вакыт арасы.



Мөхәммәдхарис хәзрәт хәзерге дөньядан хәбәрдар кеше булып, фәннәр өйрәнергә һәм телләр белергә зарур һәм кирәк дип әйтә иде диләр. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) тырышлыгы һәм максаты изһару үлфәт (Аллаһы Тәгалә юлында кардәшлек, якынлык күрсәтү), вәгазь һәм нәсыйхәт иде; гаять галим, тәкъва һәм шәйхе камил булып, Бохараи шәрифтәге мәүләнә шәйх Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтләренең хәлифәсе иде; 1870 нче елның икенче ноябрендә һиҗрия белән 1286 нчы елда шәгъбан шәрифтә сәнәи камәрия (ай елы) белән алтмыш өч яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчтеләр (рәхмәтуллаһи рәхмәтән вәсигатән); җеназасендә өч меңнән артык кеше булды һәм вафатыннан соң берникадәр мәрсияләр (кеше вафат булганнан соң, аны мактап язган шигырь, мөнәҗәтләр) язылды.

Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәттән (рәхмәтуллаһи галәйһи) соң Эстәрлебашта мәчет һәм мәдрәсәгә рәис булып Мөхәммәдхәррас хәзрәт Нигъмәтуллаһ улы (рәхмәтуллаһи галәйһи) калды. Мөхәммәдхәррас хәзрәт 1814 нче елда дөньяга килеп 1844 нче елда Бохараи шәрифкә китте. 1856 нчы елда Бохараи шәрифтән сау-сәламәт кайтып, имам булып тәгълим һәм дәрес бирү белән шөгелләнде, 1870 нче дә Эстәрлебашта хәлифә булды. Ләкин

авыруы аркасында йортыннан еш чыга алмады. 1871 нче елның 30 нчы ноябрендә илле җиде яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Мәрхүм гыйлеме белән гамәль итүче һәм шәйхе камил иде (рәхмәтуллаһи галәйһи васигатән).

Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәттән соң урынына улы Габдуллаһ мәхдүм имам булды. Мөхәммәдхаррас хәзрәттән соң урынына улы Латыйфуллаһ мәхдүм имам булды. Латыйфуллаһ мәхдүм 1878 нче елның август аенда вафат булды (иннә лилләһи һәм иннә иләйһи раҗигун). Латыйфуллаһ мәхдүмнән соң урынына тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең икенче улы Гобәйдуллаһ мәхдүм имам куелды; бу елларда Эстәрледә ахунд һәм мөдәррис Гобәйдуллаһ хәзрәт булып мәдрәсәләрдә дәрес бирүче хәлфәләрнең өстендә рәис һәм мөдир иде. Эстәрлебашта мәрхүм тархан Мөхәммәдхаррас хәзрәттән соң Эстәрлебашның шәехе булып калган кеше шәйх Зәйнуллаһ Хосраушир улы иде. (Бамир хәлфә исеме белән данлыклы) Зәйнуллаһ хәзрәт хәлифә Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтнең хәлифәләреннән булган Эстәрлетамак Шәрәфетдин[1] хәзрәтнең Чиләбе

[1] Шәрәфетдин бине Зәйнетдин әл-Эстәрлетамакый. Казанда, Бохарада һәм Эстәрлетамакта уку-укыту эшендә, шәехлектә һәм башка очракларда мулла Нигъмәтуллаһ белән бергәләп эш иткән. 1262 (1845) елның шәгъбан аенда, җитмеш җиде яшендә Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була.



якларындагы хәлифәсе Габделхаким мәрхүм хәзрәттән камиллек, рөхсәт һәм иҗазәт алып, шәехлеккә ишарәләре булганыннан Эстәрлебаш шәехе булдылар. Әмир хәзрәт 1810 нчы елларда дөньяга килде, 1827 нче елда Өфе өязе Арслан авылыннан Эстәрлебашына шәкерт булып килеп гыйлем алып мәдрәсәдә торып тәсаувыф әһеле булып, хәзрәтләрнең хезмәтендә житешеп әдәп өйрәнеп, һәрвакыт йортта һәм сәфәрдә булган вакытларында көндез һәм төнлә һәр өч хәзрәт заманында яннарында булып, гүзәл холык һәм тәкъвалык белән камиллеккә иреште. Мөхәммәдхарис хәзрәтнең хәлфәләре Мөхәммәдхафиз һәм Мөхәммәдьяр хәлфәләр үз заманында вафат булдылар һәм күбесе авылларында имам һәм мөдәррис иделәр. 1875 нче елларда мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) заманыннан калган хәлфәләрнең иң мәшһүрләреннән берсе Габдуллаһ хәлфә бине Нигъмәтуллаһ (Хаҗи Хәлфә исеме белән данлыклы) (Сарапул өязе Буби авылыннан) 1864 нче еллар чамасында Эстәрлебашка Казаннан, Мөхәммәдкәрим хәзрәт мәрхүмнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) мәдрәсәсенә килеп гыйлем һәм фәннәр өйрәнгән иде. Эстәрлебашта һәр гыйлемлеккә көч сарыф итеп, хосуси буларак фикыһ һәм әл-осуль гыйлеменә сәләтле иде; 1880 нче елларда Эстәрлебашның

иң галим кешеләреннән берсе булып санала иде. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхаррас хәзрәт заманыннан соң Эстәрлебашның күпчелек шәкерт һәм мәхдүмнәре Гобәйдуллаһ, Латыйфуллаһ, Хәбибуллаһ һәм башкалар һәр кайсылары Габдуллаһ хаҗи хәлфә мәрхүмнең шәкертләре иделәр. Габдуллаһ хаҗи хәлфә егерме елга якын Эстәрлебашта камил тырышлык белән дәрес биреп тәгълим итте. 1883 нче елда рамазан шәриф гаетеннән соң август аенда Хаҗ сәфәренә китеп шул ук елны сау-сәламәт Хаҗ кылып, Хаждан соң авырып Мәдинәи Мөнәүвәрәгә килеп авыруы артып гашурә[1] көн 1883 нче елның 2 нче ноябрендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте; кабер шәрифе Мәдинәи Мөнәүвәрәдәдер. Мәрхүм галим, гамил, тәкъва һәм гыйлем хезмәтчесе кеше иде (рәхмәтуллаһи галәйһи васигатән). Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) 5 нче улы Габделмәҗид мәхдүм иде, яшь чагыннан Минзәлә өязе Чакмак авылында булган Габдуллаһ хәзрәт мәдрәсәсендә шәкерт булып гыйлем өйрәнеп, бөтен Чакмак авылы тирә-ягында мәхәббәт хасыйл итеп, 1886 нчы елда хәзрәтләренең фатихасы белән Бохараи шәрифкә барып гыйлем һәм фәннәр өйрәнергә тотынды; 1890 нчы елда

[1] Гашүрә көне — мөхәррәм аеның унынчы көне.



Эстәрлебашның ихласлы мөридләреннән (ишан шәкерте) һәм Илек шәһәренең игътибарга лаеклы яхшы сәүдәгәрләреннән булган Гобәйдуллаһ хаҗи исемле кеше Габделмәҗид мәхдүмгә мәхәббәт күрсәтеп хәраҗат (чыгымнар, акча) җибәреп, Бохараи шәрифтән кайтарып аңа кызын бирде һәм июнь аенда никах, зөфаф һәм туй мәҗлесләре үткәрде; җәй айларын Илек һәм Эстәрлебаш арасында үткәреп, көз килгәч Бохараи шәрифкә гыйлем һәм фәннәрен камилләштерер өчен сәфәргә чыкты; 1892 нче елда Эстәрлебашка кайтып гыйлем һәм фәннәр укытуга керешге. Габделмәҗид мәхдүм дәрескә һәм тәкърирга сәләтле һәм эшендә тырыш адәм булганы өчен, дәресләр башлаганда шәкертләрнең барысы бик сөенделәр. 1893 нче елның 10 нчы мартында Хаҗ сәфәренә китте; Хаждан Мәдинәи-Мөнәүвәрәгә барып, энесе Габделкадыйр мәхдүм белән очрашып, Хаҗ тәмамыннан соң ваба авыруы белән фәкать ун сәгать авырып 1893 нче елның 12 нче зөлхиҗҗәсендә (14 нче июнендә) егерме алты яшендә вафат булды; кабере Мәккәи-Мөкәррәмәдә Җәннәти Мөгаллә исемле зираттадыр. Мәрхүм хаҗи Габделмәҗид мәхдүм гаять фазыйл, галим, юмарт һәм һәркемгә мәхәббәтле бер зат иде, гомерен гыйлем юлына сарыф итте. Аллаһы Тәгалә аз гомеренә күп саваплар бирсен (рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән).

Мәрхүм Мөхәммәдхарис хәзрәтнең өченче улы Хәбибуллаһ хәзрәт мәхдүм 1856 нчы елда дөньяга килде; яшь вакытларында Эстәрлебашында Габдуллаһ хажи хәлфәдән дәрес алып, 1872 нче елда Чакмак Габдуллаһ хәзрәт мәдрәсәсенә китте. 1872 нче елдан 1878 нче елга кадәр Чакмакта гакаидтән кайбер шәкертләргә дәрес укытып, шул 1878 нче елда Бохараи шәрифкә китте. Бохараи шәрифтә ике яки өч ел торып гыйлем һәм фәннәрне камилләштергәннән соң Үргәнечтә мәрхүм шәйх Ниязколый әт-Төркмәни хәзрәтнең хәлифәсе булган мәрхүм шәйх Мөхәммәдшәриф әл-Үргәнчи ән-Нугай хәзрәтнең улы һәм хәлифәсе булан Мөхәммәдзакир хәзрәткә яран (дус, мөрид) булып изен һәм рөхсәт алып, 1884 нче елның 24 нче августында сау-сәламәт Бохараи шәрифтән Эстәрлебашка кайтты, һәм шул ук елның ноябрь аенда Тәфсире Казыйдан дәрес бирә башлады. Дәреснең башында “Хайрукүм мән тәгалләмәл Кур-әнә вә галләмәһү” (Сезнең иң хәерлегез Коръәнне өйрәнеп, башкаларга өйрәткәнегездер) хәдисе шәрифен укып “Амин шулай булса иде” дип, нотыклар әйтеп, догалар үтенеп Бохараи шәриф тәртибе буенча ифтитах (кереш) мәҗлесе ясап дәрес башлар иде. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт Эстәрлебашта 1884 нче елдан башлап 1893 нче елга кадәр тәфсир, хәдис, осуль һәм фикыһтән, нәху һәм кәләмнән чын тырышлык



белән мәшәкать һәм кәсеб итүне ташлап ун ел кадәр дәрес бирде. 93 нче елларда инспектор тарафыннан мәнегъ (тыю) кәгазе килү сәбәбе белән бер вакытлар дәрес укытуыннан туктап торса да, 95 нче елларда министр тарафыннан рөхсәт алып яңадан дәрес укытырга кереште. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт галим, фазыйл һәм батыр сүзле кеше иде. Үргәнечтә шәйх Мөхәммәдзакир хәзрәт Мөхәммәдшәриф улы тарафыннан кешеләрне тарикатькә өндәү һәм иршад әмере бирелгән булса да, ачык итеп яран (дуслар, мөрид) тәрбияләү белән шөгыльләнмәде. “Башта заһир гыйлем кирәк: батыйн гыйлем, заһир гыйлем чиләгенә тамчы-тамчы салган суыбыздыр, әүвәл чиләк таза булсын, чиләк таза булмаса тамчылап тамган су пычранып торыр һәм файдасы да булмас; башта чиләк таза булсын, соңыннан иншаллаһ су булыр”– дип мисал китерә иде. Хәбибуллаһ мәхдүм хәзрәт амири бил-мәгъруф (кушканнарны үтәүче) һәм сахибул-гайрәт (тырышлык иясе) булып, Эстәрлебашта гыйлем таратып, 1897 нче елның 20 нче гыйнварында кырык бер яшендә вафат булды (рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән).

Тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) бишенче улы Габделкадыйр мәхдүм (1866 нчы елда дөньяга килде) башта Эстәрлебаш мәдрәсәсендә торып,

соңыннан 1889 нчы елда Хаҗга барып, Хаҗдан соң Мәдинәи-Мөнәүвәрәдә гыйлем алып һәм тасхихи кыйраәт итеп (Коръән укуын гүзәлләштереп), ике мәртәбә Хаҗ кылганнан соң 1893 нче елның 10 нчы октябрендә сау-сәламәт Эстәрлебашка кайтты; хәзерге вакытта да Эстәрлебаштагы шәкертләргә Коръәнне дөрес итеп укуны өйрәтеп һәм мәдрәсәнең мөдире булып торадыр.

Эстәрлебашта гыйлем алып бу заманнарда исемнәре офыкка таралган галим һәм голямалардан сау-сәламәт булып гыйлем бирү белән шөгелләнүче, мәчетләрдә имам булып торучы, вәгазь һәм нәсыйхәт итүчеләрнең мәшһүр һәм игътибарга лаек булганнарыннан кайберләре: Бәйрәкәдә Габделгали хәзрәт, Ялпакталда Габдуллаһ ахунд, Җаекъ кальгасында Габделсалих ахунд, Әстәрханда Габделфәрид ахунд, Күкчәтауда Мөхәммәдсадыйк мулла, Нижний Новгородта, ягъни Мәкәриәдә Сәмәрканд ахунд, Симипалада Мөхәммәдхәлим ахунд, Каргалы шәһәрендә Хәйруллаһ мәхдүмнәр һәрбере Эстәрлебашта заманында шәкерт булган затлардыр.

Эстәрлебашында хәзерге көннәрдә элеккегечә һаман уналты мәдрәсә булып, һәр ел тәгъмирләре (ремонт) һәм тәрбияләре күренеп тора; үндүрт хәлфә Гобәйдуллаһ ахунд хәзрәт Мөхәммәдхарис улының (рәхмәтуллаһи галәйһи) карамагында



шәкерт укыталар, һәр фәннән дәресләр укыла; шәкертләрнең саны элеккегедән төшкәне юк. 1897 нче елдагы гомуми санау буенча Эстәрлебаш мәдрәсәсендә кунучы шәкертләр биш йөз җитмеш кеше дип язылды. Гомуми санаудан соң кырыклап шәкерт тагын мәдрәсәгә гыйлем алыр өчен килгәннәр; мәдрәсәдә кырыкка якын яшәмичә килеп-китеп укучы шәкертләр дә бар; шул хисап белән Эстәрлебашта барысы алты йөз утыз кадәр шәкерт дәрес һәм тәгълим алып дин өйрәнү тырышлыгы эчендәдер. Эстәрлебашының яхшы якларыннан берсе: кыш көннәрендә мәчеттә, җәмәгать белән укылган намазларның күбесендә, бер имам артында мең кадәр җәмәгать җыелып намазлар үтәлә, бу Аллаһның рәхмәте һәм догаларның бәрәкәте беләндер мөгаен. Мәрхүм тархан Мөхәммәдхарис хәзрәтнең дүрт улының һәрбере Эстәрлебаш мәдрәсәләренең тәгъмир (ремонт) һәм тәртип (тәртип эчендә тоту) һәм тәрбияләре өчен тырышлык белән торалар. Аллаһы Тәгалә гыйлемгә иң югары мәртәбәләргә чыгарга, галимләргә һәм гыйлем өйрәнергә теләүчеләргә тәүфикъ һидаять бирсәң иде; падишаһыбыз император бөек Николай Александрович хәзрәтләренә озын гомерләр биреп, мөселманнарга каршы миһербан һәм шәфкатьләрне күбәйтеп, ризыкларыбызга бәрәкәт бирсәң иде, һәрвакыт гыйлем өйрәнеп,

галимнәргә игътибар биреп, гыйлемне мактау вә гыйлемлек юлында булып; үзеңнең катыңда кабул булган гыйбадәтләр белән сөенеч эчендә гомеребезне кичерсәк иде; изге, салих колларныңны телгә алган мәҗлесләрдә, иңечиге булмаган рәхмәтеңне өстебезгә файдалы яңгырлар кебек яудырып, изге, салих затларыңа кавышырга насыйп итсәң иде, дип һәр укучыдан ихласлы дога итү һәм фатиха укуларын үтенәм. Амин.

**Мөхәммәдшакир Тукаев**

**ЭСТӘРЛЕБАШ ТАРИХЫ**

Подписано в печать 27.05.10. Гарнитура «Times».
Формат 60×90 $^{1}/_{32}$. Печать офсетная.
Тираж 1000 экз. Заказ О-716.

Отпечатано в типографии филиала
ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

ISBN 978-5-904820-02-2

9 785904 820022

# تاريخ

## استرلی باش

اثر

محمد شاکر مخدوم طوقایف

اوف گوبیرنسی استرلی طماق اویزی قالقاش ولوصی
استرلی باش آولنده طرخان اوغلی محمد شاکر طوقایف

Мөхәммәдшакир ТУКАЕВ

# Эстәрлебаш ТАРИХЫ

АЛТЫН МИРАС